кубесе редакциялэрдэ эшли) белэн очрашулар да укучыны мавыктыра. Йолдыз Шэрэпова, Эхэт Сафиуллин, Рэдиф Гаташ, Нэжибэ Сафина, Нурулла Гариф һ.б. катнашында узган эдэби кичэлэр берэүне дэ битараф калдырмады.

Элеге очрашулар хакында газетага мэкалэлэр яздылар, үзлэренең ижат жимешлэре белэн таныштырдылар. Укучыларның ижади сэлэтлэрен үстерүдэ китап белэн кызыксынуның эһэмияте зур. Һэр ижат жимешен вакытында күрэ белеп, ярдэм итеп, юнэлеш биреп тору мөһим. Китапханэ каршындагы утырышларда укучылар үзлэре шигырь, экият китапчыклары чыгаралар. Үрнэк алыр кешелэр булганда, хыялмаксатларга ирешү дэ жиңелрэк.

Дэрвишлэр бистэсендэ яшэп ижат иткэн эдиплэр, ижат эһеллэренең тормышын һэм ижат юлларын өйрэнү, китапларын туплау, пропагандалау, тематик стендлар булдыру буенча күп еллар дэвамында системалы эш алып барыла. Төрле елларда безнең төбэктэ яшэп ижат иткэн Г. Минский, А. Расих, Э. Бикчэнтэева, К. Миңлебаев, Н. Фэттах хакында бай архив материалы тупланды, туганнары белэн элемтэ булдырылды. Гимназиядэ сугыштан соңгы елларда укучыларга белем биргэн, жырчы-шагыйрь, талантлы шэхес Мэхмүт Хөсэен музее ачылу зур тантанага әйлэнде. Бу эштэ укучылар, ата-аналар да актив катнашты.

Татар китабына мэхэббэт тэрбиялэүдэ күптэн сыналган нэтижэле эш алымнары белэн беррэттэн, укучыларны мавыктырырдай яңа, креатив формалар да кулланыла башлады. Шундыйлардан "Эдэби ярминкэ", "Буккроссинг", "Флешбук" кебеклэре укучыларга бик ошады һэм даими кулланылышка кереп китте. "Буккроссинг" өчен залга махсус шкафлар куелды. Шул рэвешчэ "Китапка икенче гомер бүлэк ит" акциясе яңа төсмер белэн баетылып, дэвам иттерелде. "Флешбук" кысаларында, укучылар үзлэре яраткан китаплардан цитаталар китереп, шэхси кичерешлэрен чагылдырган иллюстрациялэр ясадылар, презентациялэр эзерлэделэр. Шунысы мөһим: эш юнэлешен билгелэгэндэ, иң элек теге яки бу юнэлешнең укучыны ни дэрэжэдэ кызыксындыра алуы, үзенең эчтэлеге белэн балага якын булуы, тэрбияви эһэмияте искэ алынырга тиеш.

**Хужиэхмэтов Э.Н.**

## ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИЖАТЫ – МИЛЛЭТЕБЕЗ ПЕДАГОГИКАСЫНЫҢ АСЫЛ ӨЛЕШЕ

*Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан шэһэре*

Халык авыз ижаты һэрбер миллэтнең, халыкның мэдэни байлыгын чагылдыра. Авыз ижатын миллэтнең, халыкның кумэк акылы, сэнгатькэ сэлэте тудырган, форма ягыннан гасырлар буе камиллэштереп, сүз сэнгате югарылыгына күтэргэн.





Болгар-татар миллэтенең авыз ижаты да, башка миллэтлэрнең, халыкларның авыз ижаты кебек үк, эдэби һэм тарихи мирасыбызның гүзэл бер өлешен тэшкил итэ. Анда без ерак гасырлар тавышын да, бүгенге һэм килэчэк көннар аһэңен дэ ишетэбез.

Миллэтебез авыз ижаты эсэрлэре – яшь буынга белем һэм тэрбия бирүдэ кыйммэтле чишмэ, чыганак. Миллэтнең бай рухлы, кешелэрне гүзэл килэчэккэ рухландыручы экиятлэре, киң колачлы жырлары, тирэн фэлсэфи эйтемнэре, тапкыр һэм үткер мэкальлэре, үзенчэлекле табышмаклары, яшьлэргэ сабак бирердэй итеп ижат ителгэн риваять, дастан, легенда, эпослары, бэетлэре һэм башка күп төрле ижат жимешлэре килэчэк буынны миллэт тормышын дэвам итэрлек, аны үстерүгэ өлеш кертерлек итеп тэрбиялэүдэ зур рухи чишмэ, чыганак булып тора. Бу кыйммэтле мирасның тарихи һэм тэрбияви эһэмияте елдан-ел үсэ бара.

Миллэтебезнең күренекле мэгърифэтчелэре халык авыз ижаты эсэрлэренең зэвык, акыл, эхлакый, хезмэт тэрбияви тээсир көченэ, аларны өйрэнүнең зарурлыгына һэрвакыт зур эһэмият бирделэр. Каюм Насыйри халык экиятлэренең, бала тэрбиялэүдэге эһэмияте ягыннан, хэтта балалар өчен махсус язылган башка эсэрлэрдэн югары торганлыгын ассызыклады, үзенең мэгърифэтчелек эшчэнлегендэ алардан кин файдаланды. Чөнки, диде ул, халкыбыз авыз ижаты эсэрлэренең гадилеге, алардагы саф күңеллелек бала психологиясе үзенчэлеклэренэ туры килэ. Поль Лафарг исэ «Мэдэният тарихы буенча очерклар» дигэн хезмэтендэ халык авыз ижаты эсэрлэрен тэрбия эшендэ икелэнмичэ файдаланырга киңэш итте.

Халык авыз ижаты эсэрлэре яшь буынга тэрбия бирү чарасы булу белен бергэ, эйлэнэ-тирэ дөньяны танып белу чыганагы буларак та хезмэт итэ. Авыз ижаты эсэрлэрен үзлэштерү процессында балалар миллэтебез тарихы, аның тормышындагы эһэмиятле вакыйгалар, хэтта аларда катнашкан тарихи шэхеслэр турында да белемнэр алалар.

Татар халык авыз ижатында, башка миллэт, халыкларның авыз ижаты эсэрлэрендэге кебек үк, фэлсэфэ, тыйблык, этнография, география, педагогика, метеорология өлкэлэренэ караган шактый күп гыйлемнэр табарга мөмкин. Без халык авыз ижаты аша тормышның төрле тарафларын, үткэннең дэ, үзебез тудыра торган хэзерге көннең дэ бөек эһэмиятен тирэнрэк аңлыйбыз.

Туган тел чыганагы булган фольклор эсэрлэрен урта белем бирү мэктэбендэ өйрэнү балаларнын тел байлыгын, фикерлэү сэлэтен үстерүгэ булышлык итэ.

Болгар-татар миллэте авыз ижаты эсэрлэрен жыюга һэм өйрэнүгэ күп көч куйган күренекле мэгърифэтче һэм галим Каюм Насыйри миллэтнең рухи байлыгын тэшкил иткэн эсэрлэрне хезмэт кешесенең талантын һэм ижади көчен, килэчэккэ булган омтылышын чагылдыру ышанычлы чыганак дип санады.

Сөекле шагыйребез Габдулла Тукай да халыкыбыз авыз иҗатына олы мәхәббәт һәм тирән хөрмәт белән карады. Аның бу карашы халык иҗаты турындагы хезмәтләрендә ачык чагыла: «Халык ядъкарьлары – безнең бабаларыбыз тарафыннан калдырыл-ган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр... Белергә кирәк ки, халык җырлары – халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер», - диде ул «Халык әдәбияты» исемле хезмәтендә.

Халык авыз иҗаты бик борынгы заманнардан бирле милләт тарихына үзенчәлекле юлдаш булып килә һәм аның бәһасез мәдәни байлыгын тәшкил итә. Халык авыз иҗаты әсәрләрендә милләтнең тарихи үсеш юлында алган тормыш тәҗрибәсе, ан дәрәҗәсе һәм иң яхшы милли сыйфатлары чагыла. Халык иҗаты безгә хезмәт ияләренең дөньяга карашларын, матурлыкны аңлавын ачыкларга булыша.

Халык авыз иҗатында милли педагогиканың күп кенә мөһим нигезләре чагылыш тапкан. Югарыда әйтелгәнчә, милли педагогика дип халык авыз иҗаты әсәрләрендә, гомумән, халыкның борын-борыннан туплаган яшәү тәҗрибәсендә чагылыш тапкан, әле дә тормышта кулланып килгән педагогик карашлар, алымнар, чаралар тупланмасына әйтәләр. Халык педагогикасы милләтнең һәр яңа буынын милләт теләгән юнәлештә тәрбияләү өчен кулланыла. Милли педагогика милләт тормышын дәвам итәргә тиешле яшь буын тәрбияләү өлкәсендә туплаган тәҗрибә: гадәт, йола, ганганә, бәйрәм, дин, тарих, аш-су, киемсалым, матди һәм рухи мәдәният формаларында буыннан-буынга күчеп килә. Халык авыз иҗаты – ул милли педагогиканың гыйлем капчыгы, яшьләр яттан белергә тиеш булган тормыш дәреслеге, гасырлар дәвамында ничәмә-ничә яшь буынны тәрбияләүдә тупланган уңай тәҗрибәләр, язылмаган кагыйдәләр тупланмасы. Халык авыз иҗаты әсәрләренең бөтенесе дә диярлек яшьләргә тәрбия һәм гыйлем бирү идеяләре белән сугарылган.

Мәгълүм булганча, һәр милләтнең, һәр җәмгыятьнең тормыш итү ысуллары, гореф-гадәтләре, үзенә генә хас, үзенчәлекле, халык телендә әйтелгәнчә, «ташка баскан законнары» була. Язма яки басма теле булмаган милләтләрдә дә бу вазифаларны халык авыз иҗаты әсәрләре башкарып килгән. Язма теле туганга кадәр болгар-татар халкының меңәр елга сузылган тормыш-көнкүреш тәҗрибәсен эченә алган маддәләр, законнар, әхлак нормалары буыннан-буынга, телдән-телгә күчеп килгән фольклор байлыгында сакланган. Шулай итеп, милләтебезнең авыз иҗаты безнең өчен тарихи һәм хокукый чыганак булып тора, ул халык тормышындагы уңай йолаларны, гадәтләрне туплаган зур җыелма, әхлак кодексы вазифасын үтәп килгән һәм хәзер дә үти.

Халык авыз иҗаты әсәрләрен, гадәттә, балалар яратып укыйлар, аларны чын күңелдән, гаять көчле хисләр, тойгылар аша кабул итәләр. Чөнки халык авыз иҗаты саф балалык, мәңгелек яшьлек хисләре белән





сугарылган. Бу үзенчәлектән тәрбия максатында киң һәм нәтиҗәле файдалану сорала. Шунысы үзенчәлекле, бала башта күпмедер гомерен әкиятләр тыңлап, укып уздыра, бераз үсә төшкәч, халыкның музыка иҗатына бәйле әсәрләр – җырлар, бәетләр, такмаклар, такмазалар белән, соңрак легендалар, эпослар, дастаннар, батырлар турындагы поэмалар белән мавыгып яши.

Халык авыз иҗаты әсәрләренең һәр төренең үзенә генә хас үзенчәлекләре бар. Шуны истә тотып, теге яки бу әсәрне өйрәнү процессында аның жанрына карап, махсус алымнарга таянып эш итеlә.

Шәкертләр уку, туган тел дәресләрендә татар халык авыз иҗатының кайбер үрнәкләре белән башлангыч сыйныфларда ук танышалар. Балаларның фольклор буенча гыйлемнәре көндәлек тормышта үзара һәм өлкәннәр белән аралашу, халык иҗаты әсәрләрен мөстәкыйль уку, кинокартиналар карау, сәнгать әсәрләре белән танышу процессында тулылана бара.

Татар халык авыз иҗаты үз эченә күп төрле жанрларны ала: әкият, табышмак, мәкаль һәм әйтем, җыр, бәет, такмак, такмаза, риваять һәм легенда, кыйсса, эпос, дастан, мөнәҗәт, санамыш, тел көрмәкләндергеч, сынамыш уеннар һәм башкалар.

Халкыбызның иң әһәмиятле беренчел педагогик әсәре, һичшиксез, бишек җырлары. Аларда аналарның теләкләре, ышанычлары, баласын рухи һәм физик яктан матур, булдыклы, игелекле, мәрхәмәтле, тәүфыйклы, гадел итеп күрү өметләре чагыла. Аналарның бәгырьдән, йөрәк түреннән чыккан ягымлы сүзләре һәм моңнары ягыннан бишек җырлары тәрбиядә башка берниндн чара белән дә чагыштырырлык, алмаштырырлык түгел.

Бишек җырларыннан башлап, бәетләрдә, әкиятләрдә, мөнәҗәтләрдә, хикәятләрдә милләтебез татар кешесенен нинди булырга тиешлегенә үзенең мөнәсәбәтен белдерә, үзе омтылган, үзе теләгән үрнәкне иң гүзәл, иң күркәм, югары рухи сыйфатлар белән бизи.

Халык иҗатында тәрбиянең һәр юнәлешенә караган, кешедәге барлык әхлакый сыйфатлар хакындагы фикерләр, тәкъдимнәр, киңәшләр, үгет-нәсихәтләр, фатихалар, таләпләр бар. Аларда халыкның балаларга әхлак, зәвык, физик һәм хезмәт тәрбиясенә караганнары аеруча әчтәлекле һәм мәгънәле.

Милләтебез җырлары – күп төрле бизәкләрдән генә торган моңлы, әһәңле үзе бер дөнья. Җырларда дуслык, туганлык, халыкның кунакчыллыгы, татулык, кардәшлек һәм бердәмлек тойгылары чагыла.

Мәкаль һәм әйтемнәрнең эчтәлекләре дә бик гыйбрәтле. Аларны өйрәнгәндә яттан белү генә житми. Үсмерләрнең башкалар белән аралашканда бу мәкальләрдә әйтелгән үрнәккә омтылулары, гыйбрәт алулары мөһим.

Әкиятләр кешенең гүзәллеген, сафлыгын, аның хыялларын чагылдыра. Аларда гыйлем алу, һөнәр-кәсеп өйрәнү, дуслык, үзара ярдәмләшү, батырлык кебек күркәм сыйфатлар турында сөйләнә. Шул ук вакытта кешедәге тискәре сыйфатлар: ялкаулык, саранлык, комсызлык, көнчелек һ.б. тәнкыйть ителә.

Реаль һәм фантастик алымнар белән сүрәтләнгән кешеләр, хайваннар, мифик образлар аша милләтнең үткән тормышын, киләчәккә карата хыял һәм омтылышларын чагылдыручы чәчмә халык авыз иҗаты әсәрләре – әкиятләр дип атала. Халкыбызның авыз иҗатында әкиятләр иң бай һәм мөһим жанрларның берсе булып тора. Мәктәпләрдә әкиятләрне өйрәнү укучының зәвыгын тәрбияләргә, аның әдәби тел байлыгын, иҗади сәләтен үстерүгә ярдәм итә.

Әкиятләр – балалар арасында иң танылган һәм таралган әсәрләр. Моның сәбәбе – әкиятләрнең гаҗәеп оста иҗат ителгән, формасы эчтәлегенә тәңгәл килгән булуында һәм әкият табигатенең балалар табигатенә бик якын торуында. Шунысы үзенчәлекле: милли педагогиканың әкиятләргә салынган мөһим нәтиҗәсе төгәл һәм мавыктыргыч образлар һәм сюжетлар аша искиткеч зур осталык белән тыңлаучыга, укучыга җиткерелә. Нәкъ менә шул ягы белән әкиятләр балага, укучыларга турыдан-туры педагогик тәэсир ясый, тәрбия бирә.

Татар халык әкиятләрен педагогик күзлектән тикшереп карау халкыбызның әле бик борынгы дәверләрдә үк бала тәрбияләү мәсьәләсенә җитди игътибар бирүен күрсәтә. Халык фикеренчә, тәрбиянең төп максаты – хезмәт сөюче, бернинди явыз көчләрдән курыкмаучы, аларга каршы көрәшергә әзер торучы, бөтен яктан да камил үсешкә ирешкән көчле шәхес тәрбияләү. Мондый шәхес халкын, илен ярата, аның азатлыгы өчен корбан булырга әзер тора. Ай үсәсен көн үскән, ел үсәсен ай үскән көчле һәм акыллы батыр образларында халык үзенең тәрбия турындагы фикерләрен, теләкләрен һәм уйларын гәүдәләндергән, яшьләргә әкият батырларын мисал итеп куйган, алардан үрнәк алырга өндәгән. Әкиятләрдә без яшь буынны тәрбияләүнең төрле мәсьәләләре буенча күп кенә кыйммәтле киңәшләр, тәкъдимнәр табабыз. Мәсәлән, күп кенә әкиятләрнең асылын балага хезмәт тәрбиясе бирү, аны һөнәргә өйрәтүгә караган мөһим педагогик фикерләр тәшкил итә.

Халык ир балага да, кыз балага да бертигез итеп карауны, аларга тигез тәрбия бирүне яклый. Бармакларның кайсысы да газиз һәм кадерле, - ди олылар сүзе. Күп кенә әкиятләрдә кызларның тирән акыллы, кара көчләр, явыз дошманнар белән көрәшерлек кыю, зирәк, тапкыр булулары сөйләнә. Мондый әкиятләр яшь буында хатын-кызга карата ихтирам тәрбияләү, хатын-кызларның хокукларын аңлату өчен аеруча кыйммәтле.





Халык әкиятләрендә төп геройның явыз көчләргә каршы аяусыз көрәше, аның бәхетле киләчәккә омтылышы, матур хыяллары да, һичшиксез, чынбарлыктагы тормыш таләпләре нигезендә туганнар. Кеше үзенең тормышын яхшыртырга, көнкүреше өчен кирәк булган әйберләрне күбрәк җитештерергә һәм аларны эшләп чыгаруны җиңеләйтергә теләгән. Үзенең акыл һәм иҗат көченә таяну аңа киләчәген матур итеп кузалларга, андагы әдәби алымнар һәм чаралардан оста файдалану исә чиксез бай хыялын җәелдереп җибәрергә киң юл ачкан. Әкиятләргә хас булган шушы үзенчәлекләрне балаларга төшендерү аларга халык авыз иҗатының бу иң борынгы жанрын аңлауны шактый җиңеләйтә.

Әкиятләр темасын өйрәнгәндә, аларның ничек барлыкка килүе хакында укучыларга кыскача мәгълүмат биреп китү зарури.

Әкиятләр күп гасырлар элек барлыкка килә башлаганнар. Алар борынгы бабаларыбызнң табигать күренешләрен җанлы итеп карауны яки күз алдына китерүе нәтиҗәсе буларак килеп чыкканнар. Кешелек яшәешенең бу чорларында бабаларыбыз күп табигать күренешләренең килеп чыгуын ниндидер югары көчкә бәйләп аңлатканнар. Алар табигать күренешләрен тирән аңлый, андагы үзгәрешләрнең серләренә дөрес төшенә алмаганнар. Борынгы кешеләр табигать күренешләренең аерым төрен – үзенә зарарсыз яки файдалы булганнарын изгеләштергән, икенче төрен исә явыз көчләр, дошманнар дип аңлаган. Табигать көчләрен шул рәвешле җанлы көчләр дип карау халык әкиятләренең тарихи нигезен тәшкил итә.

Бабаларыбыз табигать кочагында, төрле җанварлар, кош-кортлар белән уртак бер тирәлектә яшәгәнлектән, хайваннар дөньясын изгеләштереп караган. Бу хәл әкиятләрнең нигезенә салынган, халыкның поэтик иҗатына күчкән. Вакытлар үтү белән халыкның аңы арта төшкән. Әкиятләрнең нигезен тәшкил иткән бу күренешләргә дә мөнәсәбәт, караш үзгәрә барган.

Татар милләте әкиятләргә бай милләт. Ул иҗат иткән әкиятләр эчтәлек һәм формалары ягыннан төп өч төргә бүленәләр: хайваннар турындагы әкиятләр, тылсымлы әкиятләр, тормыш-көнкүреш әкиятләре. Билгеле, бу бүленеш шартлы. Чөнки галимнәр, төрле үзенчәлекләренә карап, әкиятләрне тагын күп кенә төркем һәм төркемчәләргә бүләләр: мифик, легендар, героик, маҗаралы, сатирик, юмористик, новеллистик, табышмак, көлдергеч, алдавыч һ.б. әкиятләр.

Татар халык әкиятләре арасында хайваннар турындагы әкиятләр күп түгел дияргә була. Мондый әкиятләрнең төп геройлары – кыргый җанварлар, йорт терлекләре, кошлар һ.б. Хайваннар турындагы әкиятләрдә төрле хайваннарга төрлечә бәя бирелә: ат - һәрвакыттагыча, эшчән һәм кешенең якын дусты; кәҗә – тапкыр, бүре – усал һәм ангыра, арслан – көчле, төлке – хәйләкәр, аю – авыр табигатьле һ.б. Хайваннар

турындагы экиятләрдә иң еш очрый торган киек - төлке. Аннан кала аю һәм бүре. Төлке барлык экиятләрдә дә диярлек хәйләкәр, алдакчы, ялагай итеп сурәтләнә. Аю, бүре - тупас, ахмак буларак тасвирлана.

Хайваннар турындагы күпчелек экиятләр сыйнфый җәмгыять шартларында төрле төркемнәрнең үзара мөнәсәбәтләрен гәүдәләндерә. Экият эчтәлегендәге бу хакыйкатьне балаларга ача белү, төшендерү кирәк. Бу төр экиятләрнең тагын бер мөһим сыйфаты бар: аларда аллегория ярдәмендә гомумән кешеләргә хас кимчелекләр дә тәнкыйть ителә. Бу очракта хайваннарның гадәтләре, йөреш-кыланмышлары кешеләрдә очрый торган тискәре сыйфатларны күрсәтү өчен файдаланыла. Экиятләрдә ялкаулык, эш сөймәү кебек сыйфатлар аеруча көчле ирония белән сурәтләнә, хезмәт сөймәүчеләр хурлыкка калдырыла, аларга карата тискәре караш тудырыла. Яхшылыкның кадерен белмәү, игелекне оныту кебек сыйфатларны да халык кискен гаепли. Кыскасы, бу төркем экиятләрдә милләт әхлагы, аның кагыйдәләре чагылыш таба.

Тылсымлы экиятләр татар халык авыз иҗатындагы эпик әсәрләр арасында шактый зур урын алып торалар. Тылсымлы экиятләр зур күләмле булулары, күп төрле вакыйгаларны эченә алган катлаулы сюжетка корылган булулары белән аерылып торалар. Тылсымлы экиятләрнең үзләренә генә хас сәнгати алымнары бар.

Дөрес, тылсымлы экиятләрнең дә эчтәлеген чынбарлык, тормышта булган яки булуы мөмкин булган хәлләр тәшкил итәләр. Әмма аларда хыялый вакыйгалар, маҗаралар, фантастик образлар өстенлек итә, чиксез бай хыялга корылган маҗаралы һәм куркыныч эш-вакыйгаларны сурәтләү зур урын ала. Тылсымлы экиятләрдә герой төрле авыр хәлләргә юлыга. Ул коточкыч аждаһалар, канэчкеч диюләр, зәһәр һәм хәйләкәр убырлы карчыкларга, еланнарга каршы көрәшә.

Тылсымлы экият үзенә генә хас гадәти бер алым белән башланып китә. Мәсәлән, «Аучы малае» дигән экият: «Борын-борын заманда, кәҗә – командир, саескан – сотник, бака – плотник, үрдәк – үрәтник булган заманда, яшәгән икән, ди, бер аучы» дигән кереш белән башлана. Ул алым: патша уряднигының үрдәккә, сотникның саесканга охшатып сөйләнүе халыкның элеккеге җәмгыятькә нинди мөнәсәбәттә торганлыгын күрсәтә.

Тылсымлы экиятләрнең үзәгендә уңай образ – батыр, акыллы, кулыннан һәртөрле эш килә торган егет образы тора. Халыкның көче һәм аның тапкырлыгы менә шул егет образында бирелә. Ул патша, дию пәриләре, аждаһалар яки башка шуның кебек кара көчләргә каршы көрәштә һәрвакыт җиңеп чыга. Экият герое хезмәт халкының иҗтимагый, әхлакый һәм зәвык идеалларын чагылдыра. Аңа акыл иясе – картлар, курку белмәс дуслары, тапкыр һәм сөйкемле сылу кызлар, төрле серле әйберләр, кешегә ияләшкән кыргый хайваннар булышалар.





Тылсымлы экиятләрнең бер өлеше аталар һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтләрне сурәтләүдән башланып китә. Карт ата үләр алдыннан балаларына васыять итеп калдыра («Һөнәрле үлмәс», «Юләр угыл», «Өч ул» һ.б.). Ата васыятен тотмаган, икенче төрле итеп әйткәндә, өлкәннәрнең тормыш һәм хезмәт тәҗрибәләре белән хисаплашырга теләмәгән экият геройларын халык гаепли, аларны бәхетсезлеккә дучар итә. Аталарының васыятен, киңәшен тоткан уллар исә экиятләрдә мактала, алар юлларында янадан-яна уңышларга ирешәләр.

Тылсымлы экиятләрдә тормышның әчесен-төчесен татыган картлар образында халыкның бай тормыш тәҗрибәсе гәүдәләнә. Бу экиятләр балаларга тормышта өлкәннәр сүзенә, алар киңәшенә, хәер-фатихаларына игътибарлы булырга кирәклеген кисәтәләр.

Тылсымлы экиятләрнең, генетик чыганаклары никадәр генә борынгы чорга караса да, алар белән бәйле сюжет һәм мотивлар һәрвакыт заман таләпләренә җавап биргәннәр: аларда һәрвакыт кешеләрнең киләчәккә юнәлгән өмет-хыяллары чагылган. Идея һәм зәвык кыйммәте булмаса, бу экиятләр меңнәрчә еллар аша бүгенгә кадәр килеп җитә алмаслар иде. Шуңа күрә дә әлеге экиятләрдә һәр тарихи чорның үзенчәлекле эзләрен табарга була.

Күп тылсымлы экиятләрдә көмәк көч, бердәм, уртак эшләр зарурлыгы рухында тәрбияләү мәсьәләләре алгы планга куела. Экият батырлары: берәүдән икәү яхшы, икәүдән өчәү яхшы дип, бергә туплана һәм оешкан көч белән явыз җаннарга, халыкны, илне изеп яшәүче аждаһаларга, җен-пәриләргә каршы көрәшкә күтәрелә, ахырда җиңеп чыга («Камыр батыр» һ.б.). Үзара дус һәм тату яшәү, бер-береңә ярдәм итешү фикере байтак экиятләр нигезенә салынган.

Тылсымлы экиятләрдә әхлак, әдәп тәрбиясе мәсьәләсе үзәк урыннарның берсен ала. Халык экиятләрендәге батырлар – элек-электән халкыбызның, иң югары һәм иң гадел әхлак нормаларын бергә туплаган, тәрбия идеалын чагылдырган образлар алар. Халык аларны үзенең иң яхшы әдәп кагыйдәләренә нигезләнеп тудырган. Бу батырлар явыз көчләр символы булган аждаһа һәм дию пәриләре, җеннәр белән үлем сугышы алып барганда да мәһәббәт ир һәм гадел кеше булып калалар. Экият батыры йоклап яткан диюне үтерүне үзе өчен түбәнчелек итеп саный. Экият батыры никадәр генә көчле булмасын һәм кайда гына булып, нинди генә батырлыклар эшләмәсен, ул үз милләтеннән аерылмый, аның алдында җаваплылык хисен онытмый, батырлыгын үз милләте хакына эшли. Әгәр дә батыр, үз-үзен яратуга бирелеп яисә алтын-көмешкә алданып, матур кызга кызыгып, иленә, милләтенә, иптәшләренә хыянәт итсә, ул каты һәм гадел җәза ала. Экиятләрдә изгелекнең җирдә ятып калмавы, явызлыкны һәрчак җиңеп чыгуы тасвирлана.

Әкият эчтәлегендә һәр җинаять милләт тарафыннан бердәй каты җәзага дучар ителми. Әхлак тәрбиясендә гафу итү, гаепне эш белән аклау алымнары да булган. Әгәр кеше эшләгән җинаятен, хатасын чын күңелдән таный икән, әгәр ул үзендә гаебен эш белән акларлык көч таба икән, бу әхлак нормаларына ярашлы булган һәм гафу ителгән. Мондый эчтәлектәге тылсымлы әкиятләр аша халык-педагог балаларның иң нечкә хис-тойгыларына тәэсир иткән, шул ук вакытта үз-үзенне генә яратуның, намуссызлыкның, шәхесне түбәнәйтүен ачып биргән.

Тормыш-көнкүреш әкиятләрендә, нигездә, милләтнен көндәлек тормышында булган вакыйгалар тасвирлана. Бу әкиятләрдә сыйнфый җәмгыять шартларында яшәгән кешеләрнең уй-теләкләре, карашлары, омтылышлары, изүче сыйныфка каршы алып барылган азатлык көрәше чагылдырыла. Бу төр әкиятләрдә вакыйгада катнашучыларның, сыйнфый аң дәрәҗәсе туктаусыз үсә, дөньяга карашы кинәеп баруы җанлы картиналарда күрсәтелә. «Шомбай», «Күке кычкыргач, котүче хезмәт хакы ала» кебек әкиятләр бу яктан аеруча үзенчәлекле.

Тормыш-көнкүреш әкиятләрендә азатлык өчен көрәш алып баручы унай образ аеруча җылылык, тирән мәхәббәт белән сүрәтләнә. Бу төр әкиятләрдә геройлар тормышның үзеннән алынган халык вәкилләре – таз, кыю солдат, мәрхәмәтле көтүче, унмаган килен, усал кайнана һ.б. Мондый әкиятләрдә явыз, комсыз кешеләргә, ялганчы дин әһелләренә киң күнелле, игелекле геройлар каршы куела. Тормыш-көнкүреш әкиятләрендә ялкаулык, саранлык, куркаклык һәрвакыт кешеләрдәге иң начар сыйфатлар буларак күрсәтелә. Мисалга «Куркак кеше» әкиятен китерү дә җитә. Анда үз борыны сызгырудан куркып, урманнан качып кайткан кеше образы көлке объекты итеп алына.

Җыр халык тарафыннан яратып иҗат ителә. Аның кешеләр өчен юлдаш, якын иптәш, рухи юаныч, көчле тәрбия чишмәсе булуын беләбез. Халык җырлары гаҗәеп образлы. Җырларда кешенең матурлыгы ай, кояш белән тинләнә, яшьләрнең гүзәллеге сандугач, был-был, күгәрчен, карлыгач кебек кошларга охшатып мактала.

Халык җырлары моннан бик күп гасырлар элек иҗат ителә башлый. Аларның иң борынгылары эш, хезмәт процессына бәйле рәвештә туган. Җырлар халкыбыз тормышындагы һәм тарихында-гы иң әһәмиятле вакыйгалар хакында да сөйли.

Җырларда милләт тормышының, көнкүрешенең, гореф-гадәтләренең төрле яклап чагылышын, аның матурлык тою сәләтен, дөньяга карашының гәүдәләнешен күрәбез. Җырларда халык үзенең туган җиренә, туган иленә, батырларына булган мәхәббәтен чагылдыра, шатлыгын һәм кайгы-хәсрәтен уртаклаша.

Җыр – халкыбызның борын-борыннан килгән тормыш юлда-шы. Кеше күңеленең төрле халәтендә туган җыр-моң, - үзенең вазифасын һәм кулланышы ягыннан милләтнең көндәлек тормышына, аның уй-





кичерешләренә аеруча якын булган иҗат төре. Халык авыз иҗатының башка төрләреннән аермалы буларак, җыр һәркемнең үзе белән яши. Аны кәефнен төрле чагында, теләсә кайда җырларга, һич тә булмаса, көйләргә мөмкин. Җыр белән ир-егетләр яуга киткән, яудан кайткан; төрле кунак-туй мәҗлесләрендә, иң беренче булып, җыр һәм уен кораллары тавышы янгыраган һәм бу хәзер да шулай. Халык үзе әйткәнчә, җыр тормышта куаныч та, юаныч та биргән. Халык тормышында җырның әһәмияте гаять зур. Халык җырларында күп буын вәкилләренә хас һәм уртак хисләр, кичерешләр салынган. Җыр кешенең рухын, күңелен баета. Тормыштагы һәм сәнгатьтәге матурлыкны тоярга, күрергә, яратырга өйрәтә. Кешеләргә җыр көрәшергә, искене җимереп, яңаны төзергә булыша. Халык җыр белән авырлыкларны, хәтта үлемне да җинә.

Татар халык җырлары, нигездә, төп өч төргә бүленәләр: тарихи, тормыш-көнкүреш һәм мәхәббәт җырлары.

Татар халык иҗатында тарихи җыр – барысыннан да элек ил язмышына, милли, гражданлык һәм сугышчан тарихына бәйле булган мөһим вакыйгалар хакында, бу вакыйгаларда катнашкан милләт батырлары, күренекле шәхесләр турында хикәяләүче иҗат төре. Тарихи җыр – үзенең холкы ягыннан тәгаен тарихи вакыйга җирлегендә туган лиро-эпик әсәр; анда халык язмышына бәйле вакыйганы хикәяләү дә, ул хакта уйлану да бергә үрелеп килә. Тарихи җырлар – ватанны яратуны гәүдәләндергән эчтәлекле һәм героик пафос белән сугарылган кыйммәтле мирас. Бу җырларның, эчтәлегендә чагылыш тапкан төп тема – туган ил һәм халык бердәмлеге.

Татар халык җырларының, икенче төркеме: тормыш-көнкүреш җырлары. Тормыш-көнкүреш җырларының, төп үзенчәлеге шуннан гыйбәрәт: анда, җырның лирик герое милләт тормышның көндәлек вакыйгаларына, гаилә мөнәсәбәтләренә бәйле булган хис һәм тойгыларны башкалар белән уртаклаша. Мондый җырлар милләтнең көндәлек тормышына якын тора, геройның рухи дөньясын, шәхси кичерешләрен чагылдыра. Тормыш-көнкүреш җырларының төп эчтәлеген табигать матурлыгына соклану, туган якны ярату, сагыну, иҗтимагый тигезсезлеккә нәфрәт, гомернең кадерен белергә чакыру һ.б. тәшкил итә. Халыкның туган иленә, туган җиренә булган мәхәббәте җырларда күп төрле поэтик бизәкләр ярдәмендә бирелә.

Өченче төргә кергән лирик җырларның зур өлешен мәхәббәт һәм хатын-кыз язмышы турындагы җырлар алып тора. Алар тирән кичерешле һәм образларның гаять камил булулары белән җыр классикасының мәңге югалмас үрнәкләрен тәшкил итәләр.

Сөю, мәхәббәт хисе һәркем өчен газиз, анлаешлы, ул кеше күңеленнән, йөрәгеннән җыр булып ургылып чыга. Мәхәббәт җырларының төп эчтәлеге бер-берсен сөюче кыз һәм егетнең тойгы һәм хисләрен жит-

керүдән гыйбарәт. Җырларның күп кенә өлеше ир-егетләр күңелендәге тойгыны тасвирлау белән бәйле. Әйтик, ир-егет сөйгән кызының сылу гәүдәсен, аның матурлыгын образлы сүзләр, чагыштырулар ярдәмендә күз алдына китереп бастырырга омтыла. Күп кенә җырларда гадәти образлар һәм эпитетлар ярдәмендә егет йөрәгенә ут кабызган кыз идеаллаштырыла: сөйгән ярның кашы кара, буе зифа, бер бите ай, бер бите кояш, аның кыйгач кашы хәтта айны көнләштерә. Шул ук вакытта кызның сафлыгын тасвирлауга да зур урын бирелә, аның әдәпле һәм тыйнак булуына басым ясала.

Халык иҗаты өчен күңел төшенкелеге бөтенләй ят нәрсә. Татар халкының шаян җырлары, уен җырлары мона ачык мисал. Хезмәт халкы гасырлар буе изелеп, кайгы-хәсрәт, мохтаҗлыкта яшәгән хәлдә дә хөр һәм көр күңеллелеген саклап кала алган. Бу исә халык рухының көче, якты киләчәккә ышанычы, өмете турында сөйли. Сан ягыннан караганда, татар халкының шаян җырлары артык күп түгел. Әмма алар хәтта иң авыр заманнарда да халыкның якты киләчәккә ышанып, өмет һәм күңел күтәренкелеге белән яшәвен күрсәтә. Шаян җырлар тормыштагы һәртөрле көлке күренешләргә халыкның карашын белдерә, аерым кешеләрдәге кимчелекләрне күрсәтә, шәхестә уңай кешелек сыйфатларын тәбияләргә булыша.

Халыкның тормыш тәҗрибәсе, дөньяга карашы, тирән, акылы әхлак нормалары бигрәк тә афористик иҗатында, шул исәптән мәкальләрдә тулы чагыла.

Мәкаль дип телдән-телгә күчеп йөрүче, халыкның зур тормыш тәҗрибәсен туплаган тәрбия эчтәлекле, кыска һәм образлы сөйләмнәргә әйтәләр. Татар халык авыз иҗатында мәкальләр шактый зур урын алган, тормышта нык таралган һәм киң кулланыла торган жанр исәпләнә. Тәмамланган тирән фикернең, образлы һәм тапкыр итеп бирелүе мәкальләрне гаять үтемле жанрга әйләндергән, көндәлек сөйләм процессында киң кулланылудан тыш, алар язма әдәбият әсәрләре тукымасына да шактый үтеп кергәннәр.

Мәкальләр, гадәттә, тормышта очрый торган күренешләргә, вакыйгаларга карата кешеләрнең аңында туган фикер йомгагы, нәтиҗә буларак барлыкка киләләр. Мәкальләрнең идея-тематик эчтәлеге гаҗәеп дәрәҗәдә киң. Аларда милләтебез тормышының бөтен төрле яклары диярлек чагылыш тапкан.

Матур һәм тирән мәгънәле итеп әйтелгән мәкальне һәркем үз фикере кебек кабул итүе, яратып куллануы мәкаль һәм әйтемнәрнең тиз таралуына һәм халык күңелендә озак вакытлар саклануына китерә.

Туу вакытлары ягыннан мәкальләрнең тарихы бик еракка барып тоташа. Кайбер мәкальләрдә мифологик элементлар яки карашларның чагылуы (җен, убыр, тәңре, шайтан һ.б.), коллар, ханнар, каннар, биләр һәм алар арасындагы мөнәсәбәтләрнең тасвирлануы шуны раслый.





«Байның карыны тук, колы белән эше юк», «Крестьянның җаны – алланыкы, тәне – патшаныкы, аркасы – алпавытныкы, шуннан калган газаплар – бар да үзенеке», «Байларга көн дә бәйрәм, көн дә туй, ярлыларга көн дә хәсрәт, көн дә уй», «Елан койрыксыз, бай боерыксыз булмас», «Барма бәйгә, үзе килер өйгә», «Кайсы ыру көчле, ханны шул куя», «Хан килә, хан артыннан кан килә», «Хан күп булса, яу күп булыр» кебек мәкальләрнең сыйнфый җәмгыять тормышында иҗат ителүе күренә, аларда кешеләрнең кешене изүе һәм бирәүләрнең икенчеләр хисабына көн күрүләре ачык чагыла.

Мәкальләрнең төп максаты – кешеләргә, бигрәк тә әхлак һәм әдәп тәрбиясе бирүгә багышланган. Татар халык мәкальләрендә яшь буынны тәрбияләү буенча үзенчәлекле милли яклар белән бергә бөтен кешелек өчен хас булган гомуми фикерләр дә чагыла.

Мәкальләрнең дә төп темасы – туган ил, туган җир. «Үз илең – алтын бишек», «Иле юкның – көне юк», «Чит илдә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул», «Ир-егет үзе өчен туа, иле өчен үлә» һ.б.

Халык мәкальләрендә шулай ук хезмәт, акыл һәм һөнәрчелек темасыда киң урын алып тора. Халыкның хезмәткә, гыйлем алуга, һөнәркәсепкә өйрәнүгә омтылышын чагылдырган, уңганлыкны, тырышлыкны данлаган һәм ялкаулыкны, наданлыкны фаш иткән мәкальләр бик күп. Мәкальләрдә ялкау, булдыксыз, бушка шапырынучы кешеләр каты тәнкыйтькә дучар була.

Тормыш-көнкүреш тәҗрибәләрен чагылдырган мәкальләрдә халыкның гасырлар буе формалашкан милли йолалары, гореф-гадәтләре, ганганәләре чагыла. Бу яктан бигрәк тә акыл белән эш итү, әхлак, тәрбия һәм гаилә мөнәсәбәтләре турындагы мәкальләр бик үзенчәлекле.

Мәкальләрнең тормыштагы ролен балаларга аңлатып бирү тәрбияви яктан бик файдалы. Аларны өйрәнү, хәтердә калдыру, урынлы файдалана белү безнең сөйләмебезне баета, зэлекле фикерләвебезне үстерә, камилләштерә, халыкка, туган телебезгә мәхәббәт, гүзәл сыйфатлар тәрбияли.

Табышмаклар-мәкальләр һәм әйтемнәр кебек үк, халыкның афористик иҗат төре. Халык табышмакларын өйрәнү педагогик яктан әһәмияткә ия. Ул укучыларга өстәмә мәгълумат биреп, тормышны танып-белергә өйрәтеп кенә калмый, шәкертләрдә игътибарлылык, күзәтүчәнлек сыйфатлары тәрбияли, аларның зэлекле һәм образлы фикерләү сәләтен үстерүгә булыша, тел байлыгын арттыра, туган телгә мәхәббәт тәрбияли.

Табышмак – табигать дөньясындагы, халыкның тормыш-көнкүрешендәге барлык җанлы һәм җансыз әйберләрне һәм күренешләрне, исемен атамыйча, читләтеп сүрәтләүгә корылган, я булмаса, шаян сорау, хәйләкәр мәсьәлә рәвешендә төзелгән, күп вакытта шигъри формага салынган кечкенә күләмле халык авыз иҗаты әсәре. Табыш-

мак – туры уйлап, уратып әйтелгән образлы сөйләм ул. Шул образлы сөйләмнән тыңлаучылар уйланылган предметны эзләп табарга тиешләр. «Табышмак» – «табыш», «табу» ягъни табарка кирәклек сүзеннән ясалган.

Табышмакларның барлыкка килүе борынгы «яшерен тел» белән бәйләнгән дип аңлатыла. Борынгы кешеләр табигать дөньясын жанлы итеп күз алдына китергәннәр. Имештер, кырларда, урманнарда, тауларда, елга һәм күлләрдә ниндидер акыллы затлар яшәгән, алар кешеләргә төрлечә зыян кылып торганнар. Менә шул дошман көчләрне алдау өчен кешеләр «яшерен тел» уйлап чыгарганнар. Ауга чыгар алдыннан хайваннарны һәм коралларны үз исемнәре белән атау тыелган, чөнки борынгы аучы хайваннарны кешечә сөйләшә белә дип уйлаган. Кайбер хайваннарның исемнәрен әйтергә ярамау икенче бер ышану белән дә бәйле: имеш, йорт ияләре һәм урман, кыр ияләре үзара дошманлашып яшәгәннәр. Әгәр йорт иясе «биләмәсендә» берәр киек хайван исеме әйтсән, тегесе, ачуланып, кешегә зыян китерә, янәсе. Менә шуңа күрә яшерен телдә күп кенә киекләрнең кеше үзе өчен генә аңлый торган «алмаш» исемнәре булган. Мондый «алмаш» исемнәр татар халкының кайбер ышануларында соңгы вакытларга кадәр сакланып калганнар. Мәсәлән, сарык бәрәннәре булган урында «куян» дип әйтү тыелган. Әгәр әйтсәң, бәрәннәр «үлеп бетәчәк» икән. Шундый казаны булдырмас өчен куянга төрле «алмаш» исемнәр тапканнар: «кыр тәкәсе», «озын колак», «чая тәкә», «кыртый» һ.б.

Яшерен телдә, табышмакта әйберләрнең исемен атамыйча, читләтеп әйтәләр һәм бу бер үк төрле чаралар ярдәмендә эшләнә. Мәсәлән, еланга «озын агай» диләр.

Озын, озын эз килер, озын буйлы кыз килер, кабыклары калтырап, мангайлары ялтырап.

Борынгы бабаларыбыз, үз ыруына «бәла-каза китермәс өчен», яшерен телне яхшы белергә тиеш булган. Ә яшерен телне өйрәнүдә табышмаклардан файдаланганнар. Борынгы заманда табышмаклар хезмәт халкының тормышын, дөньяга карашын, гыйлем хәзинәләрен чагылдыру чарасы булганнар, кешенең акылын сынау вазифасын үтәгәннәр. Кешегә үзенең ижат көчен тулырак куллану мөмкин булмаган ул заманнарда. Табышмаклар аеруча киң кулланылган. Төрле бәйрәмнәр, ял вакытлары, күңел ачу кичләре һ.б. еш кына табышмак әйтешү ярдәмендә үткән.

Табышмакларның борынгы вазифалары яшерен телгә өйрәтү, акыл сынау белән генә чикләнмәгән. Халык авыз ижатын өйрәнүчеләр табышмакларның сихерчелек ролен дә үтәгән булуларын әйтәләр. Борынгы бабаларыбыз табышмак ярдәмендә табигать көчләрен сихерләп, буйсындырып була дип уйлаганнар. Ауга чыгар алдыннан табышмак әйтешү гадәте яшәгән.





Табышмакның тылсымы белән бәйле тагын бер гадәт яшәгән. Аны теләсә кайсы вакытта әйтү ярамаган. «Юкса, файда урынына зыян китәсен көт тә тор». Халык телендә менә мондый әйтем дә йөри: «Табышмакны көндез әйтсәң, бүре очрый», имеш.

Бәетләр – татар халык ижатына гына хас милли жанр. Борынгы төрки халыклар ижатында да, башка милләтләрдә дә бәетләр белән бер рәткә куярдай, аларга тәңгәл килердәй жанр юк.

Ике юллы тезмә әсәр гарәпчә «бәет» дип атала. Бәетләр йөзләрчә ел буена халыкның тарихын, аның тормышында булган вакыйгаларны, хезмәт кешесенең кайгы-хәсрәтен, авыр тормыш шартларына нәфрәтен һәм киләчәккә булган якты теләкләрен чынбарлык жирлегендә чагылдырып килә.

Халык тормышына нигезләнеп ижат ителгән бәетләр – хезмәт ияләре ижаты, халыкның рухи байлыгын чагылдырган сәнгать әсәрләре ул. Яшь буынга гыйлем һәм тәрбия бирүдә бәетләрнең мөмкинлекләре зур.

Халык авыз ижатының лиро-эпик төренә кергән бәетләр, гадәттә, әһәмиятле тарихи вакыйгалар (сугыш, крестьяннар чуалышы, баш күтәрүләр) яки гадәттән тыш фажигале хәлләр (көтелмәгән үлем, һәлак булу) уңае белән барлыкка килгәннәр. Алар арасында «Хәерниса бәете», «Гражданнар сугышы бәете», «Комсомолец Рәхи бәете», «Бөек Ватан сугышы бәете» һ.б. бар. Бәетләрдә гәүдәләнгән образларның прототиплары булган. Шулай да алар арасында тәгаен вакыйгалар белән бәйләнгәннәре да бар. Бәетләрдә төп урынны трагик яки киеренке драматик эчтәлекле әсәрләр алып торса да, сатирик яки юмористик эчтәлекле бәетләр да очрый. Бәетләрнең иң зур өлеше төрле язма чыганакларда: борынгы кульъязмаларда, истәлек дәфтәрләрендә сакланып калган.

Совет чорында халык авыз ижатының күпчелек жанрлары жентекләп өйрәнелсә дә, билгеле сәбәпләр аркасында, бер өлкә фәнни тикшеренүләр гел читтә кала бирде. Бу – халыкның дини ышануларын, хыялларын, идеалларын чагылдырган әсәрләр. Андый әсәрләр халык хәзинәсендә бер дә аз булмыйча, фольклорның һәрбер төренә (хәтта бишек жырларына да) мөнәсәбәтле булса да, гыйльми жыентыкларга алар кертелмәде диярлек. Бу бик үкенечле хәл. Чөнки дини-суфичыл халык ижаты әсәрләренең чыганагы булган, фольклорның нәкъ менә шушы үзенчәлекле әсәрләрен саклаучы буын бүген бетә бара: XX гасыр башында дини мәктәп-мәдрәсәләрдә белем алган, саф мөселман ата-аналар кулында тәрбия күргән хәзерге әби-бабайлар буыны инде бик аз санда калды. Алар белән бергә фольклорыбызның кыйммәтле ядкарьләре дә мәңгелеккә китеп, онытылуга дучар булалар. Бу телебез саега дигән сүз.

Дини эчтәлекле әсәрләр арасыннан иң игьтибарга лаек төр – ул мөнәҗәтләр. Кеше мөнәҗәтне Алла белән берьялгызы калып "серләшкән" вакытта әйткән, кеше Аллага мөрәҗәгать итеп, гөнаһларын ярлыкауны сораган, бу дөнья һәм ахирәт хакындагы уйларын аңлаткан.

Дини мөнәҗәтләрдә (мөнәҗәтләрнең дини эчтәлек алмыйча, аерым бер иҗтимагый-фәлсәфи мәсьәләгә яки фаҗигале хәлге багышланганнары да бар) берничә зур тема күзгә ташлана:

1. Алланы, изгеләрне, пәйгамбәрләрне зурлау;

2. Мөселманның үлемнән, әҗәлдән курку тойгысы, бу дөньяның фанилыгы, ахирәттә Алла каршына килеп җавап тоту зарурлыгы, шул сәбәпле аңа мөрәҗәгать итеп, ярдәм һәм рәхим-шәфкать сорау;

3. Мөнәҗәт әйтүченең тыңлаучысына турыдан-туры нәсихәте, үгет бирүе, вәгазь уку. Мондый мөнәҗәтләрдә мөселманга фарыз эшләр, исламның әхлак кагыйдәләре шигъри юлларга салынып, үтемле һәм тәэсирле итеп искә төшерелә:

Шайтан сиңа сөялмәсен,
Тезгенеңне бәйләмәсен,
Хакка дошман әйләмәсен,
Укы Коръән илә намаз.
(«Укы Коръән илә намаз») һ.б.

Менә бу милли әдәбиятыбызда сакланган мөгаллимнең суфыйчылык тәгълиматындагы сигез вазифасын санап үтү дә бик урынлы булыр. Бу да бит халык авыз иҗатындагы бер жанр булып санала ала торгандыр.

1. Мөгаллимнең беренче вазифасы – балаларга охшарга тырышу, аларны үз балаларың кебек күрү.

2. Мөгаллимнең икенче вазифасы – закон үрнәгенә юл сабу: үз хезмәтеңә мактаганны, рәхмәт әйткәнне көтмә, аңа хезмәт хакы көтмә, аңа рәхмәтле булма.

3. Мөгаллим беркайчанда шәкерткә киңәш бирүдән баш тартырга тиеш түгел, әгәр бала бу дәрәҗәдә эшләргә әзер булмаса, ул моңа юл куярга тиеш түгел.

4. Мөгаллим баланы яман эштән тыю, чикләү өчен турыдан туры, дорфа итеп түгел, ә, бәлкем, читләтеп, аңа теләктәшлек күрсәтеп киңәш итәргә тиеш. Турыдан туры тыю, чикләү балада кирелек тудыра, игелеклелекне кимetә.

5. Кайсы да булса фән нигезләрен эстәрүче мөгаллим башка фән нигезләре турында шәкертләргә тискәре фикер әйтмәскә тиеш.

6. Мөгаллим шәкертең сәләте аңларнык дәрәҗәдән чикләргә тиеш түгел, аның авылы аңламый торганны таләп итмәскә тиеш. Юкса ул бу гамәлләре белән шәкертнең бу гыйлемнәрне кабул итмәүен арттыра һәм акылын чикли.





7. Мөгаллим үзе балалардан тыйганны эшләргә тиеш түгел, юкса ул үз сүзләренең ялган булганын исбатлаячак.

8. Мөгаллим акылга зәгыйфь шәкертләренә алар аңнарлыкны гына бирергә тиеш.

**Шайдуллина Г.Ф.**

## ПРОЕКТНАЯ И ИССЛЕДОВАТЕЛЬСКАЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ НА УРОКАХ ХИМИИ И БИОЛОГИИ

*МБОУ «Мурзинская средняя общеобразовательная школа» Апастовского муниципального района Республики Татарстан, с. Эбалаково*

Умения и навыки исследования, полученные в детстве, легко переносятся в дальнейшем во все виды деятельности. Поэтому актуальным в педагогическом процессе сегодня становится повышение качества образования, использование методов и методических приемов, которые сформируют у школьников навыки самостоятельного добывания новых знаний, сбора необходимой информации, умения выдвигать гипотезы, делать выводы и строить умозаключения. Задача современного образования – формирование таких качеств личности как способность к творческому мышлению, самостоятельность в принятии решений, инициативность. Чтобы добиться высокого результата в обучении, необходимо научить детей мыслить, находить и решать проблемы, используя для этой цели знания из разных областей, коммуникативные и информационно-технологические умения. Этим обусловлено распространение в школах методов и технологий на основе проектной и исследовательской деятельности обучающихся. Я опишу свой педагогический опыт работы в этом направлении.

Детям младшего и среднего подросткового возраста важны не отдельные занятия, а непрерывный процесс деятельности, который удовлетворяет любознательные потребности ребенка. Планирование, конструирование, изучение, исследование, поиск, участие в конкурсах, в деловых творческих играх – все это формирует активную жизненную позицию подростка. Чтобы дать возможность ребенку поверить в свои силы, способности, знания, проявить одаренность – во всем этом помогает метод проектов.

Метод проектов называют технологией четвёртого поколения, который позволяет реализоваться обучающимся с различным уровнем обученности, творческим потенциалом и индивидуальными способностями. Метод проектов позволяет эффективно спланировать изучение темы, разносторонне представить предмет изучения, оригинально пре-